**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 елның 30 декабре № 112

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында»гы 2020 елның 30 нчы сентябрендәге 8 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 сентябрендәге 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында»гы 2020 елның 30 сентябрындагы 8 номерлы карарына (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 сентябрендәге 99 номерлы карары белән кертелгән

үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 январыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «16 390 күләмендә (уналты мең өч йөз туксан) һәм айлык 9 180 сум (тугыз мең йөз сиксән) сум күләмендә акчалата бүләк» сүзләрен «17390 (унҗиде мең өч йөз туксан сум) һәм ай саен 13420 (унөч мең дүрт йөз егерме) сум күләмендә акчалата бүләк» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 январыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «16390 (уналты мең өч йөз туксан) сум» сүзләрен «17 390 (унҗиде мең өч йөз туксан) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «2022 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2023 елның 1 январыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәре» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының
2022 елның 30 декабрендәге
112 номерлы карарына кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФА ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМНӘРЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре** | **хезмәт хакының айлык күләме, сум** |
|---|---|
| Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 16 876 |
| Әйдәп баручы белгеч | 14 084 |

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606753915 СОВЕТ БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1620001253 КПП 162001001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ